# Яшьләр авазы
# Голоса молодых

Выпуск №1

Казан
«Рухият» нәшрияты
2009

ББК 84 (2Рос=Тат)-4
Я95

На обложке:
*рисунок Рената Хусаенова (Актаныш), 14 лет, лауреат III степени*

Я95 Яшьләр авазы=Голоса молодых // Выпуск I. – Казань: Рухият, 2009. – 72 с., илл. – 16 с. (на тат. и рус. яз.)

ISBN 978-5-89706-129-7

«Рухият» рухи яңарыш фонды тарафыннан 2009 елда уздырылган «Сандугач сайрар илем» исемле XII балалар иҗаты фестивале кысаларында Алабуга шәһәрендә әдәби һәм рәсем сәнгате конкурслары уздырылды. Китап сөючеләр игътибарына шушы бәйгеләрдә җиңгән балаларның иң яхшы иҗади эшләре тәкъдим ителә.

В 2009 г. в рамках XII фестиваля детского творчества «Страна поющего соловья» фонда духовного возрождения «Рухият» в г. Елабуга состоялись Литературный конкурс и конкурс Изобразительного искусства. В данном сборнике представлено творчество победителей этих конкурсов.

ISBN 978-5-89706-129-7
© «Рухият» нәшрияты, 2009

# Ышанам!

«Татнефть» ААҖнең «Рухият» рухи яңарыш фонды 1997 елдан башлап нефть төбәгенең «Сандугач сайрар илем» исемле балалар иҗаты фестивале уздырып килә. 2007 елдан шушы фестиваль кысаларында ике елга бер мәртәбә яшь иҗатчылар бәйгесе уздырыла башлады. Әлеге китапта шушы бәйгедә катнашкан балаларның иҗади эшләре урын алган. Җыентык ике телдә. Рус телендә иҗат итүче балаларның барысы да диярлек шәһәрнекеләр. Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә, Алабуга, Түбән Кама... Язганнарында шәһәр тәрбиясе, шәһәр тәэсире әллә каян сизелеп тора. Шәһәрчә уйлауны да, шәһәрчә фикер йөртүне дә, әйләнә-тирәгә шәһәрчә мөнәсәбәтне дә тоемларга була. Ә инде татарча язган балаларның язмышлары кайсыдыр яклары белән барыбер авылга килеп тоташа: Зәй, Сарман, Әлки, Минзәлә, Азнакай районнары, Башкортстанның Борай районы... Аларның кайсылары авылда яши, укый, кайсылары авылда туган, авылда яшәгән, хәзер инде шәһәргә күчеп килгәннәр. Ни генә булмасын, аларның әсәрләре авылны, аның табигатен, андагы самимилекне, матурлыкны хәтергә төшерә... Шулай да яшь иҗатчыларны, татарча язамы ул, русчамы, туган җиргә, туган илгә мәхәббәт хисләре, әдәбият-сәнгатьне ярату, матурлыкка, гүзәллеккә омтылыш берләштерә.

Минем үземә малайларның, кызларның әдәби осталыклары, шулай ук төрле жанрларга мөрәҗәгать итүләре, пьеса, хикәя кебек катлаулы жанрларга курыкмыйча тотынулары ошады, балаларча фикер йөртү белән бергә, өлкәннәргә генә хас җитди уйланулары сокландырды.

Бала үз гомерендә бер генә шигырь, хикәя, әкият язып караса да, ул инде хыялллана, фикер йөртә, уйлана белә дигән сүз. Ул инде, иманым камил, гомере буена иҗатка, әдәбиятка, сәнгатькә, матурлыкка омтылып яшәячәк. Дөрес, әлеге балаларның күбесе, үсеп җиткәчтен, бөтенләй башка һөнәр дә сайларлар, башка өлкәләрдә эшләп йөрерләр. Әмма иҗади башлангыч, иҗат оеткысы аларның күңелләреннән берчакта да китмәячәк. Киресенчә, дөньяга, тормышка, әйләнә-тирәгә шигъри караш яшәргә, гомер итәргә, дөнья күтәргә ярдәм итәчәк. Андыйларга яшәү дә, эшләү дә, кешеләр белән аралашу да бик күпкә җиңелрәк булачак. Әдәбиятка, сәнгатькә мәхәббәтле кеше – матур күңелле, тормышны яратучан, бөтен яктан да камил шәхес ул.

Малайларның, кызларның әлеге җыентыкка туплап бирелгән әсәрләрен мин бик рәхәтләнеп укып чыктым. Шундый сәләтле балаларыбыз булуын, аларның шундый иҗат активлыгын, битараф кешеләр булып үсмәүләрен, дөньяга, җәмгыятьтәге вакыйгаларга үз мөнәсәбәтләрен күреп, шуңа сөенә-сөенә укыдым. Алар моннан соң да безне, өлкәннәрне, сөендереп яшәрләр дип ышанам.

*Роберт Миңнуллин,*
*Татарстанның халык шагыйре*

# Абашева Динара Рөстәм кызы



1992 елның 24 гыйнварында Башкортстан республикасының Борай районы Бакалы авылында дөньяга килә. 1999 елда гаиләсе белән Татарстан республикасының Алабуга шәһәренә күчеп килә.

1999 елда Алабуга шәһәренең 11 нче урта мәктәбенә укырга керә. 2004 елда мәктәпне 1 нче татар гимназиясенә кушу сәбәпле, 1 нче гимназиядә белем ала башлый.

Яраткан шөгыле – хикәяләр, шигырьләр язу. Шулай ук астрономия һәм археология белән бик кызыксына. «Сандугач сайрар илем» фестиваленең III дәрәҗә лауреаты.

## *Очрашу*

Тып-тып… Кичтән ява башлаган яңгыр төн буе яуды. Өй кыегыннан тамган тамчы тәрәзә алдындагы калайга тама. Картлар йортында яшәүче Галимә әби әнә шул тамчы тавышын төн буе тыңлады, ничек кенә йокларга тырышса да, күзенә йокы кермәде. Караваты янындагы өстәлендә торган сәгатьне ничә тапкыр алып карагандыр – тизрәк таң атканын көтте. Көткән кешегә вакыт озак үтә, диләр бит, таң атарга әле байтак сәгать бар. Ул йоклап калырга тиеш түгел, ничә еллар көткән очрашу минутын йоклап каламы соң?! Әнә күрше караватта яткан Минсафаның көтәр кешесе булмагач, тыныч кына, бер кайгысыз йоклый. Ә Галимә әбинең өч улы бар, алар инде әниләре янына берничә еллар килмәсәләр дә, Галимә әби аларны барыбер көтә. Менә бит, көтә торгач, Алланың рәхмәте, кече улы кичә хәбәр җибәргән, иртәгә киләм, дигән. Тәрбияче бу хәбәрне килеп әйткәч, Галимә әбинең сөенүен күрсәгез иде, һәрбер бүлмәгә кереп шатлыгын уртаклашты. Иртәгәсе көннең җитүен түземсезлек белән көтте. Аның кече улы, арада иң яраткан улы – Фәниле киләчәк. Ничә ел күрмәгәч, үзгәргәндер инде, тик Галимә әбинең күңелендә ул әнә шул соңгы тапкыр, җиде ел әлек күргәндәге кебек саклана.

…Урамда сирәк кенә узган машина тавышлары ишетелә, яңгыр да туктарга уйламый. Әнә шулай ята торгач, Галимә әбинең уйлары еракка, туган авылына кайтып китте.

Тормыш иптәше Фәһим белән бик тату гомер кичерделәр алар. Яшьтән үк бер-берсен яратып кавыштылар. Чит җирләргә китеп урнашырга мөмкинлекләре булса да, нишләптер туган җирне, туган авылны үз итеп, шунда төпләнеп калдылар. Бер-бер артлы өч уллары туды. Гаилә зурайгач, дүртпочмаклы өйдә кысанрак дип, Фәһиме зур итеп алтыпочмаклы өй төзеде. Үзе мәктәптә балалар укытты, ә Фәһиме авылда бригадир иде. Балалары да берсеннән-берсе матур, акыллы булып үстеләр, ата-ана сүзеннән беркайчан да чыкмадылар. Күпләргә үрнәк булырлык тату гаилә иде алар авылда. Балалар үсә торды, авылдан шәһәргә китеп укырга керделәр, армия сафларында хезмәт итеп кайттылар. Үзәкләргә үтеп керерлек җылы хатлар яза иде алар армиядән. «Әти-әни, дөньяда сездән дә кадерлерәк кем бар, без сезне өзелеп яратабыз, сагынабыз, беркайчан да ташламаячакбыз». Их, әнә шул язган сүзләре фәрештәләрнең «Амин» дигән чагына туры килмәгәндер инде, югыйсә, менә шулай ялгызы калып, картлар йортында яшәп ятмас иде.



Фәһим бик иртә дөнья куйды. Кинәт кенә йөрәге тотып үлеп китте. Олы уллары гына башлы-күзле булырга өлгергән иде. Күрәчәкне күрми гүргә кереп булмый, диләр бит, Галимә әбинең күрәчәкләре алда булган икән ул! Олы малае, өйләнеп, Себер якларында төпләнде, уртанчысы да, абыйсы янына барып урнашып, шунда төпләнде. Әни диеп өзелеп торган улларны әйтерсең алмаштырдылар, елына бер-ике тапкыр гына хат язсалар, шуңа хуш. Кечесе абыйларыннан калышмады, Себергә үк булмаса да, якындагы шәһәргә урнашты. Бик матур татар кызына өйләнде, әниләре янына еш кына кайтып йөрделәр. Галимә әби кече улы янында булганга, кайтып йөргәнгә сөенде. Улларының балалары туды, ул дүрт оныкка әби хәзер.

Галимә әбигә, яше барган саен, ялгыз яшәве авырлашты. Ерак коега суга барырга, кышларын кар көрәргә кирәк. Фәниле: «Әни үзебезгә генә яшәргә кил, ялгыз интегеп көн итмә», – дигәч, ризалашты. «Машина алырга акча җитми бит әле, әни, авылдагы өйне сатыйк», – дигәч, аңа да ризалык бирде. Өр-яңа машина алып куйды улы. Бар нәрсә дә җитеш, яшәргә дә яшәргә. Тик шул көннән Галимә әбигә генә авыр көннәр башланды, килен өчен әби артыкка әйләнде. Әбинең үксеп-үксеп елаулары ешая башлады. Улы килен сүзеннән чыкмады, әбине күрше шәһәрдәге картлар йортына урнаштырдылар, нишләптер үзләренең шәһәрендәгесенә дә түгел.

Менә шул көннән башлап җиде ел буена Галимә әби картлар йортында. Бер улы да әби янына килеп карамады. Якты дөньяга тудырган, күкрәк сөтен имезеп, назлап, төннәрен йокламыйча, елатмыйча сөеп үстергән, укытып кеше иткән ана бер баласына да кирәкмәс булды. Алар килмәсә дә, ана барыбер аларны үзенчә күңеленнән яратты, һәрберсен күңеле белән эшкә озатты, каршылады, һәр көнне ул аларны көтте. Бүген килмәделәр, бәлки, иртәгәсен килерләр әле, дип күңелен юатты. Шул уй белән ел артыннан ел үткәрде. Әле дә тәрбиячеләре әйбәт, яшәгән җирләре җылы, чиста, яхшы ашаталар, әби-бабайлар өчен өзелеп торалар. Тик… Барыбер йөрәк үзенекен итә, сагынуны, туган җирне, балаларны өзелеп сагынуны берни дә алмаштыра алмый.

…Әбинең уйларын тәрәзәдән төшкән яктылык бүлде. «Таң ата, Аллага шөкер, таң ата», – дип сөйләнә-сөйләнә, караватыннан күтәрелде ул. Иртәнге сигезгә килеп җитәм, дип хәбәр биргән бит Фәниле. Саклап кына торган иң матур күлмәген киде, кайчандыр Фәниле бүләк иткән яулыкны табып бәйләде. Озакламый калганнар – бүлмәдәгеләр дә уянды: барысы да беләләр бит бүген Галимә әбинең улы киләсен.

Менә ишектә тәрбияче Алия күренде, аның артыннан башын аска игән, чәчләренә әзрәк чал йөгергән ир-ат ияргән. Галимә әбинең йөрәге кысылыпкысылып алды. Улы, аның улы, Фәниле килгән. «Улым!» – диеп өзгәләнеп, ана улының кочагына атылды. «Әнием, йөрәгем минем, гафу ит мине, гафу ит! Мин сине өзелеп сагындым, синең өчен авылдагы өебезне яңадан сатып алдым, без синең белән анда кайтырбыз, бергә яшәрбез, мин синнән башкача аерылмам, әни», – дип өзгәләнеп кабатлады. Сүз әйтергә дә өлгермәгән Галимә әбинең кечкенә гәүдәсе улы кулыннан идәнгә таба шуып төште. Фәнил калтыранган куллары белән әнисен күтәрергә тырышты…

Галимә әбинең ничә еллар түзгән, көткән кечкенә йөрәге мондый шатлыкны, очрашуны күтәрә алмады: туктап калды. Әнисенең өстенә ятып, өзгәләнеп-өзгәләнеп елаган улын юатырга бер кеше дә кузгалмады. Ә нәрсә дип әйтә алалар соң алар аңа?! Өч улы була торып, картлар йортында тилмергән ананы алар күбрәк аңлый иде…

## Гabделхакова Айгөл Фаил кызы



1995 елның 7 ноябрендә Әлмәт шәһәрендә туа.

Әтисе – нефтьче, әнисе – укытучы.

2004 елда Р.Фәхретдин исемендәге татар гимназиясенә укырга керә. Беренче шигырьләре гимназиядә туа.

Айгөл хәзер 8 нче сыйныфта укый. Җырларга, шигырьләр укырга, төрле бәйгеләрдә катнашырга ярата. «Сандугач сайрар илем» фестиваленең III дәрәҗә лауреаты.

### *Безнең Әлмәт*

Безнең Әлмәт гел мактала
Кара алтыны белән.
Әлмәтемә җырлар язам
Йөрәк ялкыны белән.

Әлмәт – безнең туган төбәк,
Кара алтын каласы.
Үз йорты кебек ярата
Аны һәрбер баласы.

### *Хәйрия елы*

Гел яхшылык кына эшлик,
Күңел яхшылык көтә.
Игътибарлы, шәфкатьле бул,
Яхшылыкка ни җитә.

Бер яхшылык мең бәладән
Коткара, яхшылык кыл!
Сүз белән түгел, эш күрсәт,
Шул булыр әйбәт акыл.



## Гaзизова Гөлназ Рамил кызы



1991 елның 25 июлендә Азнакай районы Татар Шуганы авылында туа.

2 нче класстан әкиятләр, шигырьләр яза. Аның әкиятләре, шигырь-хикәяләре «Көмеш кыңгырау», «Ватаным Татарстан», «Маяк» газеталарында басыла. Ул рус һәм татар телендә иҗат итә. Гөлназның «Ватаным Татарстан» газетасында басылган «Кыш бабай» әкияте 1 нче урын, «Көмеш кыңгырау» газетасында «Яңа елга – яңа әкият» конкурсында «Бөдрәҗонның конкурста җиңүе» әкияте шулай ук 1 нче урын ала. Гөлназ район, республика конкурсларында да дипломнар һәм мактау кәгазьләре белән бүләкләнә. «Сандугач сайрар илем» фестиваленең II дәрәҗә лауреаты.

### *Беренче кар*

Беренче кар әллә ничек ява
Мин атлаган туры сукмакка.
Җирнең кара йөзен каплар өчен,
Төшәдер ул нурлы җиһаннан.
Җирдән кемнәр генә йөрми бүген,
Ул да түзми инде, карала...
Ләкин бүген ялган чисталыкка
Беренче кар ява да ява...
Беренче кар, син әле саф бүген
Яңа туган үксез баладай,
Берүзеңә калып шушы җирдә,
Караласың әле бик күп бар.

### *Тормыш көзе*

Мин яратам көзнең ачы җилен,
Сөям аның көчле салкынын.
Туң җирләрдән ялгыз килгән чакта,
Тоям төсле соңгы сулышын.
Мин яратам көзнең салкыннарын,
Әйтерсең җир уйлар уйлады –
Ниләр булды узган көздән бирле?
Нигә бу ел озак йоклады?
...Тормышларда да бит көзләр җиткән,
Ачы җилләр уйный күңелдә,
Әйтерсең лә көзләр иртә җитте,
Яшәр идең һаман җәйләрдә...

## *Хыял кызы*

Күрегезче, мин гап-гади хыял кызы,
Мин күкләрдә телим яшәргә.
Юк, кирәкми, зинһар, кирәкми
Үзегезгә мине дәшәргә.
Күрегезче, мин кояшны үбәм,
Күк болытны кочам кулымда.
Йолдыз һәм ай белән җитәкләшеп
Әйлән-бәйлән уйныйм болында.
Болытлардан болытларга сикереп,
Җил-агайны йөгерәм үртәләп.
Ул елмаеп бармак янап кала,
Юри генә мине шелтәләп.
Кайчагында мин дә, айга утырып,
Үткәнемне уйлап сызланам.
Шул чагында никтер авыр сулап
Киләчәгем диеп уйланам.
Ә кешеләр табигатьне сүгә:
«Көн-төн яңгырява, туктамый».
Ваемсызлар... хыял кызы түккән
Күз яшьләре диеп уйламый.
Ә мин бит гап-гади хыял кызы,
Мин күкләрдә телим яшәргә.
Юк, кирәкми, зинһар, кирәкми
Үзегезгә мине дәшәргә.



# Газизова Гөлфинә Илһам кызы



1998 елның 21 июнендә Сарман районы Җәлил бистәсендә туа. Китаплар укырга, төрле кичәләрдә катнашырга ярата. «Рухият»ның әдәби бәйгесендә катнашып III дәрәҗә диплом яулады.

## *Кар нинди була?*

*(Хикәя)*

Урманда бер бик кызыксынучан Куян баласы яшәгән. Ул ямьле җәй көннәрендә туган, ә кыш кергәндә әле бәләкәй булган. Бәләкәй булгач, ул кышның нәрсә икәнен дә белмәгән. Карт куяннар аңа күп нәрсәләр сөйләгәннәр, өйрәткәннәр, ә Куян баласы яртысын да аңламаган. Бик бәләкәй булган шул әле ул.

Барысы да шул турыда сөйләгәч, Куян баласы да кар яуганны бик көткән. Кар нинди була икән соң ул? Бик йомшак була, диләр, койрык кебек микәнни? Салкын да була, диләр, әллә ул кар тау асты чишмәсе кебек микән? Бәлки, ул кишер кебек баллыдыр, тәмледер? Шыгырдап тора, дип тә сөйләделәр, кәбестә яфрагы кебек микән әллә ул кар? Эх, тизрәк яусын иде инде ул, монда Куян баласы аны көтә-көтә арып бетте бит инде...

Көннәрдән бер көнне Куян баласы йокысыннан иртәрәк уянды. Киерелеп-сузылып җибәрсә, ни күрсен – соры туны юкка чыккан бит! Әллә нишләгән бит ул: йөгерек тәпиләре дә, озын колаклары да, йомшак койрыгы да бөтән төрле төскә кергән! Менә нинди була икән ак төс! Кар да яумады микән, дип урамга караса, исе киткән: бөтен дөнья яп-якты, күзләрне камаштыра! Кар кояш нурында җем-җем итә, ялтырый, шундый матур инде менә!

Хәзер Куян баласы белә инде: кар ул бик йомшак та, каты да була, кирәк чакта ул суыта да, җылыта да, ул бик салкын да була, бик тиз эреп тә бетә ала икән...

## *Урман җәнлекләре*

«Кышын нәрсә ашарбыз?» – дип,
Көздән үк кайгыралар,
Ояларын ныгыталар,
Мех туннарын яңарталар –
Урман җәнлекләре алар.

Тиен чикләвек киптерә,
Керпе үзенә алма ташый.
Төлке белән Бүре генә
«Кышын нәрсә ашарбыз?» – дип,
Күзләр буе башын кашый.

## Гыйләҗева Илүзә Ягъфәр кызы



1993 елның 8 апрелендә Әлмәт шәһәрендә туа. 2000 елда Р.Фәхретдин исемендәге татар гимназиясенә укырга керә. Хәзерге вакытта 10 нчы сыйныфта белем ала. Үзенең иҗади эшчәнлеге кайчан башланганын сизми дә кала. Күңел халәтен шигъри юлларга салу аңа яшәргә көч өсти. Шигырьләрендә тормышчан темалар урын ала. Буш вакытларында шигырь язарга, җырларга ярата. Киләчәген иҗат белән бәйләргә ниятли. «Сандугач сайрар илем» фестиваленең III дәрәҗә лауреаты.

### *Тату гаилә*

Сеңлем белән без икәүбез,
Икебез дә бик тату.
Һәркем өчен әйбәт сыйфат –
Татулыкны ярату.

Татулык булганда гына
Җылы кебек өебез.
Һәр балага, гаиләгә
Без татулык телибез.

### *Укытучыларга*

Укытучылар – белем бирүчеләр,
Зур хөрмәткә лаек кешеләр.
Гомер буе алар онытылмый,
Күңел киштәсеннән төшмиләр.

Алар биргән белем, осталыкны
Күңел төпләренә салырбыз.
Гомер узган саен, барысын да
Берәм-берәм искә алырбыз.



## Закирова Айгөл Рамил кызы



1992 елның 12 мартында Минзәлә районы Тупач авылында дөньяга килә. Шигърият белән 3 нче сыйныфта кызыксына башлый. Бүгенге көндә Балалар иҗат үзәгенең журналистика дәресләренә йөри. Шулай ук «Актаныш FM» радиосында һәм «Актаныш таңнары» газетасында штаттан тыш хәбәрче булып тора. «Сандугач сайрар илем» фестивалендә Гран-прига лаек булды.

***

Ташлы юлда тамчы хисем җуеп
Кулга алам комлы туфрак – соргылт җирне.
Түгеп узган яшьләр нәрсә булыр –
Мин югалткан сөю микән, яшерен серме?

Ап-ак каурый очыргандай, талгын җырга
Вак таш сибәм. Ефәк ябам ялан тезгә...
Күк хуҗасы алтын ай һәм зур йолдызлар
Гомер җырын көйләп төшә минем эзгә.

Бердәнберме, меңнән берме мин үткән юл?
Түтәл-түтәл гөлләр үсә күңелемдә.
Ташлы юлда хисләремне эзләп таптым,
Сукмактагы ике чыкка үрелдем дә...

***

Ач йөрәккә учлап сөю салсаң,
Бәлки, туяр иде...
Илтифатсыз карашыңнан күзләр
Җылы тояр иде...
Ерым-ерым уелгандыр җанга
Учларыңның сыры.
Бармы икән сөюләрнең очы
Яки нәзек кыры?..
Күбәләкләр канатына өрәм
Кайнар сүзләремне...
Урамнардан эзлә, яме, минем
Яшел күзләремне.

***

Тәрәзәне ялмап, елап,
Бөртек-бөртек
Яңгыр коя, кашагалар
Киртек-киртек...
Гөнаһ тулы җирдән атлыйм –
Адәм эзе...
Җилдә ыргый сыпылган ак
Калфак җебе...
Шайтан суын йотым-йотым
Йоткан дөнья,
Бак, селкенләп исерек тупыл яфрак коя...
Берәрсенең әллә инде зур туемы?
Алтын башак – кәләш, җир –
Кияү куены...

***

Бу соңгы тамчы иде бугай,
Соңгы өзелмәгән кылы сөюнең.
Агу булды шәраб савытына
Ваклап салган хисләр төенең...

Иреннәрне яндырдылар, куллар пеште.
Ялкын иде учларымда, ә мин түздем.
Соңгы ымсыну, соңгы җыр... Безнең сөю
Ноталарын җанда искән җилләр өзде.

Син зур дулкын идең диңгеземдә.
Хәзер ак күбексең... Өрсәм –
Куыкларың шартлар кебек...
Көлке!
Хәтереңдә калган булса әгәр,
Җаным көлен кыйблаларга селке...

***

Толымнарга уралган да буыннарга сеңгән,
Диварларның ташын ялап көзге җиргә иңгән
Күз яшьләре...
Таш тишәрдәй эре яңгыр тамчылады,
Күкләр ярып алтын яшен камчылады –
Җир яшьләнде...
Иреннәрдән бүртеп кан ташыды,
Күк капусына ашкындың, ярсу йөрәк!
Мин дәшмәдем...
Тулпар атның бәкәлләрен сыпырдым да
Ярсу хисләр урманына
Ут өстәдем...
Ах, өзелмәс җан кылларын тапый-тапый
Нечкәрттеме көз җилләре,
Әллә яңгыр?
Көзләр, елак күзләр аша басма салып,
Йөгерә-атлый бер кил әле
Чаңгыр-чаңгыр...
Төн карасын өмет ялы ак итмәде,
Өзелерлек дәрәҗәдә
Нечкә иде...
Син, мин – бергә! Бу ал таңдай зур хыялым
Өндә түгел, төштә иде.
Төштә иде...



# Митаева Гүзәлия Минхат кызы



1991 елның 7 июлендә Чистай районының Татар Сарсазы авылында эшче гаиләсендә туа. Хәзер Әлмәт дәүләт нефть институтының икътисад һәм идарә факультетында укый. Мәктәптә укыганда ук инде шигырьләр яза. «Сандугач сайрар илем» фестиваленең III дәрәҗә лауреаты.

### *Мин яратам үз телемне*

Мин яратам татар телен,
Анам теле булганга,
Һәр сүзеннән җанга якын
Нур бөркелеп торганга.

Мин яратам татар телен,
Бабам теле булганга,
Күңелемнең иң түрендә
Айдай балкып торганга.

Мин яратам татар телен,
Милләт теле булганга,
Һәрчак кирәк үз телеңне
Яратырга, зурларга.

### *Казаным!*

Әй син, Казан! Әй син, якты Казан!
Нур сибәсең Идел ярыннан.
Шәмдәлләрдә янган шәмнәр сыман
Балкып тора мәчет манараң.

Әй син, Казан! Әй син, моңлы Казан!
Илһам алган Сәйдәш моңыннан.
«Әдрән», «Карурман»нар синдә туган,
Еракларга моңың таралган.

Әй син, Казан! Дәрт вә дәрман синдә,
Син кыйбласы татар иленең!
Үзең затлы, телең татлы булып,
Дан, шөһрәт казансын исемең!

### *Сагынып кайтам*

Мин Чулманда тудым, шуңа микән,
Сулар агышларын яратам.
Саг(ы)ну-сагышларым күңелемнән
Җырлар җырлый-җырлый таратам.

Кама буе, бөдрә таллар шаулый,
Кошлар кунып сайрый талларга.
Авылымның матур мизгелләрен
Саг(ы)нып кайтам туган якларга.

# Насретдинова Динә Җәмил кызы



1995 елның 17 августында туа. Әлмәт шәһәренең Р.Фәхретдин исемендәге 1 нче гимназиясендә белем ала. Шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр иҗат итә. Беренче шигырен 7 яшендә яза. Инде 10 яшендә «Без 4 «Б» дан» дип исемләнгән, ә соңрак «Рәхмәт сиңа, Әлифбам» китаплары басылып чыга. «Тәмле төш» шигыре белән районкүләм конкурста 1 нче урынны ала, республика күләмендә III дәрәҗә диплом белән бүләкләнә. «Тәмле төш» белән район кысаларында үткән «Ау! Яшь талантлар!» бәйгесендә шулай ук III дәрәҗә диплом ала. Экологик әкияте белән Россиякүләм конкурста 3 нче урынга лаек була. 2008 елда «Ана догасы» шигыре белән 1 нче урынны яулый. «Сандугач сайрар илем» фестиваленең III дәрәҗә лауреаты.

### *«Дүрт»ле*

Илнур мәктәптән кайтты:
«Әни, мин алдым дүртле».
Әни әйтә: «Алдалама,
Хәйләкәр төлке төсле.
    Мин күрдем көндәлегеңдә
    Тора ике икеле.
    Зур дүртле һәм зур бишле
    Анда бит юк шикелле».
«Әни, математиканы
Син әллә белмисеңме?
Икегә икене кушкач,
Дүртле була түгелме?»

### *Көз яшьләре*

Көз яшьләре, тыелыгыз –
Сез әрәмгә китәсез.
Әмма җанны бушатырга
Тик сез ярдәм итәсез.
Көз яшьләре, тыелыгыз –
Кешеләр бит янымда.
Әмма күпме әрнү, рәнҗү
Хәзер минем җанымда.
Көз яшьләре, тыелыгыз –
Хәзер елау кирәкме?
Ник соң тынычландыралмыйм
Үксеп янган йөрәкне?

*2009*

### *Көзге урман*

Көзге урман, көзге урман
Бигрәк матур киенгән.
Кызгылт-сары, ал бизәкле
Шәлләренә төренгән.
Алтын алкаларын таккан,
Кызыл алмалар чиккән.
Алтын көзнең урманнары
Бигрәк матур икән.
Урман тып-тын, ишетелә
Бары яфрак шаулавы.
Яфракларның серләрен һич
Җиңел түгел аңлавы.
Сары паласы урманның
Барысын каршы ала.
Бу паласның өсләренә
Һәркем юлларын сала.
Яфрак асларыннан гөмбә
Эшләпәләре күренә.
Тезелешеп утырганнар,
Иелеп, син өз генә.
Күк йөзләре кызгылт-сары,
Кояш байый, сүрелә.
Кояш артларында ап-ак
Вак болытлар күренә.
Көзнең табигате матур,
Көз төсләре – сары, ал.
Көз тиз үтә, кыш та җитә,
Матурлыкка хәйран кал.

*2007*



# Низамов Илнур Илгизәр улы



1993 елның 8 июнендә Бөгелмә районының Зеленая Роща авылында дөньяга килә.

2000 елда авыл мәктәбенең 1 нче сыйныфына укырга керә. Хәзер 9 нчы сыйныфта укый. Сыйныфтан тыш эшләрдә дә актив катнаша. Мәктәпнең «Каурый каләм» түгәрәгенә йөри. Кайбер язган әкиятләре «Бөгелмә авазы» газетасы битләрендә басылып та чыга. Моннан тыш спорт түгәрәкләрендә дә шөгыльләнә, техника белән кызыксына. Киләчәктә авылда яшәячәк. Шуңа күрә авыл хуҗалыгы өчен кирәкле булган һөнәр сайларга тели. «Сандугач сайрар илем» фестиваленең III дәрәҗә лауреаты.

### *Кыш һәм Яз*

*(Әкият)*

Борын-борын заманда яшәгәннәр, ди, дүрт туган: Яз, Җәй, Көз һәм Кыш. Алар тату яшәгәннәр, һәркайсының үз вакыты булган. Кешеләр дә ел фасылларының үз вакытында алмашынуын яхшы белгәннәр һәм бәйрәмнәр үткәргәннәр. Ләкин берзаман Кыш – дүртенче ел фасылы – үзенә бирелгән вакытны бик аз дип санап, үз урынын Язга бирергә теләмәгән, ди. Шуңа күрә Җиргә үзенең салкын бураннарын җибәрүне туктатмаган. Яз аптырашта калган, чөнки ул үз туганыннан мондый эшне бер дә көтмәгән. Калган туганнары белән сөйләшкәннән соң, Яз Кышны ярышка чакырырга булган. Ул: «Кайсыбыз ярышта җиңеп чыга, шуның вакыты дәвам итәчәк», – дигән. Кыш тагын буранннар туздырган, ә Яз Кояштан ярдәм сораган.

Кешеләр дә көннәрнең җылынмавына аптыраганнар, ди. Алар үзләренчә Язга ярдәмгә килгәннәр: Нәүрүз бәйрәме уздырганнар, җыр-биюләр белән күңелсез көннәрен онытырга теләгәннәр. Кешеләрнең шулай зарыгып Язны көтүләре Кышны тагын да ныграк ачуландырган.

Үзара тату яшик, дип, калган ел фасыллары да ярышны карарга килгәннәр. Башта Яз белән Кыш йөгерешеп караганнар, аннары җыр-биюдә үзләрен күрсәткәннәр. Яз һәркайсысында өлгеррәк тә, җитезрәк тә икән. Кыш, бик нык арып-талып, җиңелүен танырга һәм урынын Язга бирүен белдерергә мәҗбүр булган.

Дуслар, үзегез дә күрәсез, кайчак Кыш хәзер дә үзен күрсәтеп ала әле.

### *Кояш белән Болыт*

*(Әкият)*

Борын-борын заманда яшәгәннәр, ди, Кояш белән Болыт. Алар бик тату булганнар, имеш.

Беркөнне Кояш белән Болыт очрашып сөйләшкәннәр, ди.

Болыт әйткән:

– Мин синнән көчлерәк.

– Юк, дускай, без икәү булганда көчле, – дигән Кояш.

– Шулай да мин көчлерәк. Мин хәзер сине бөтенләй каплыйм.

– Кирәкми! Мин бит кешеләргә бик кирәк! – дигән, ди, Кояш.

– Нәрсәгә? Алар синнән башка да яши ала бит.

– Син мине капласаң, бөтен җирне караңгылык басар, ә кешеләр караңгыда берни эшли алмыйлар.

– Шулай шул. Менә шуңа инде мин сине каплыйм. Кешеләр өчен мин кирәклерәк булам, – дигән дә Болыт, Кояшның җавабын да көтеп тормыйча, тиз генә эшкә керешкән.

Кояш, ничек кенә тырышмасын, үз нурларын Җир йөзенә җибәрсә дә, дустына каршы берни дә эшли алмаган. Дөнья караңгылыкка чумган. Кояш кешеләрне кызганган, ләкин нишләргә соң? Ул шунда ук бер фикергә килгән һәм бик нык кыздыра башлаган. Болыт бу эсселеккә түзә алмаган, таралган. Кояш яңадан Җиргә үз нурларын җибәргән, әмма алардан шундый эссе булган. Үсемлекләр мондый кызуга түзә алмыйча корый башлаганнар. Кешеләр дә күктә Болыт кисәгең эзләгәннәр, ди.

Болыт, бу хәлне күреп, Кояш янына ашыккан, ярдәм итәргә теләгән һәм үзенең тамчыларын сипкән. Җир йөзендә яңадан тыныч тормыш урнашкан. Моннан соң Кояш та, Болыт та бәхәсләшмәскә сүз куешканнар, ди. Шулай да кайчак йә бик эссе, йә бик яңгырлы булгалый: әллә Кояш белән Болыт бәхәсләшәме?



## Садыйкова Луиза Азат кызы



1992 елның 25 июлендә Әлмәт шәһәрендә гаиләдә икенче бала булып дөньяга килә. Нәни чакта ук бик тыныч, акыллы бала була. Өйдән ерак түгел генә «Радуга» дигән балалар бакчасына йөри. 1999 елны, бакча белән саубуллашып, Р.Фәхретдин исемендәге татар гимназиясенә укырга керә. 4 нче сыйныфта спорт түгәрәгенә йөри башлый. Хәзер дә гимназия тормышында бик актив катнаша. Спортта, журналистикада, төрле фәнни конкурс-конференцияләрдә, олимпиадаларда төрле урыннарга ирешә. Алдагы тормышын язуга, тикшеренүгә багышларга өметләнә. «Сандугач сайрар илем» фестиваленең III дәрәҗә лауреаты.

### *Дөрес юл*

*(Драма дүрт пәрдәдә)*

Катнашалар:

Расих абый – 50 яшьтә. Бай. Үз фирмасы бар.

Миләүшә апа – 45 яшьтә. Расихның хатыны. Иренең компаньоны.

Ләйлә – 25 яшьтә. Расихның олы кызы. Укымый, эшләми.

Айгөл – 20 яшьтә. Расихның кече кызы. Студент.

Фәрит – 20 яшьтә. Айгөл белән бергә укый.

Марат – 22 яшьтә. Ярлы студент. Айгөлнең балачак танышы, күршесе.

Халит – 20 яшьтә. Фәритнең дусты.

#### Беренче пәрдә

Фатирдагы бүлмә. Сәхнә уртасында зур диван, читтәрәк олы көзге, идәндә кыйммәтле келәм. Ләйлә белән Айгөл сәхнә уртасына чыгып сөйләшә башлыйлар.

Ләйлә *(көзге алдында бөтерелеп)*. Айгөл! Ишеттеңме? Кичә яңа показ мод булган ич! Уф... Дискотекада күңел ачып, күрми калганмын! Нишләргә инде, ә? *(Кычкырыбрак.)* Син мине ишетмисеңмени?

Айгөл. И апам! Ишетәм лә, тик колагым шиңә сине тыңлап. *(Авыр сулыш алып.)* Бер дә юньле сүз сөйләмисең. Мода да булган икән эш!

Ләйлә *(аптырап)*. Конечно! Мин, в отличии от некоторых, үземнең гардеробымны бик төпченеп сайлыйм. Синең көзгегә караганың бармы соң?! Гаиләбез ярлы диярсең. *(Айгөлнең күлмәген тарткалап.)* Бу сиңа килешми.

Айгөл. Әйе! Мин бөтен яшьлегемне кием сайлап, егетләр карап, күңел ачып кына уздырмыйм! *(Тавышын күтәребрәк.)* Кешенең эчке дөньясы да үсәргә тиеш.

Ләйлә. Ха! *(Ирештереп.)* Эчке дөнья, эчке дөнья! Кемгә кирәк ул? Олигархка кияүгә чыгар өчен тиешенчә кыяфәт тә ярый.

Айгөл. Фи... Олигарх. Анысы тагын нигә? Иң мөһиме... *(Әзрәк кыенсынып.)* Мәхәббәт!

Л ә й л ә. Оппа! Тукта-тукта. Әллә инде сеңелкәшемнең миннән сере бармы? *(Елмаеп, кырына утыра.)*

А й г ө л. Син көләсең лә ул, ә мин... Ә мин... Эх! Аңламассың шул.

Л ә й л ә *(үпкәләп)*. Сөйләмәсәң ни. Миңа барыбер.

А й г ө л *(кулыннан тотып)*. Үпкәләмә инде. Ярар, сөйлим. Миңа Фәрит ошый. *(Әзрәк туктап.)* Мин дә аңарда кызыксыну уятам бугай. *(Хафаланып.)* Ай!.. Ул бит хәзер килергә тиеш.

Л ә й л ә *(сеңлесенең кыяфәтенә карап)*. Киттек, бәла. Хет кешегә охшатып калыйм үзеңне. Марш минем бүлмәгә! *(Көлемсерәп.)* Хәзер красавица итәбез сине.

Айгөл һәм Фәрит.

Ф ә р и т *(барган җиреннән туктап калып)*. Фәрештә дип торам. Айгөл! Син бүген нинди матур!

А й г ө л *(елмаеп)*. Әйдә һава сулап керәбез. Урамда шундый рәхәт.

Җитәкләшеп чыгып китәләр.
Паркта. Эскәмиядә Фәрит белән Айгөл утыра.

Ф ә р и т. Карале, синең күзләрең күк төсле. Ничек элек мин моны күрмәгәнмен?

А й г ө л. Фәрит, никтер элек син генә мине белергә дә теләми идең. Ә хәзер... Хәзер нәрсә үзгәрде? Гаиләнең матди хәле моңа сәбәп түгелме?

Ф ә р и т *(сүзен бүлдереп)*. Эх, Айгөл, Айгөл! Мин альфонска охшаганмыни? Нигә алай мине рәнҗетәсең? Син ялгышасың!

А й г ө л *(егеткә елышып)*. Гафу ит, зинһар! Мин чынлап та ялгышканмын.

М а р а т керә.

Ф ә р и т. Хе! *(Мыскыллы тавыш белән.)* Карагыз әле, кем килә?

Марат асфальт себерә, Фәрит Айгөл янында үзен бу егеттән өстен күрсәтергә тырыша.

Батюшки! Бу бит теге хәерче улы. Карагыз-карагыз! Нинди чын ир-атлар эшен башкара бит ул! Ха-ха! *(Кычкырып.)* Эй, ты! Ник монда йөрисең, ә! Әллә проблемаларың әзме? Тузаныңны бүтән җирдә себер. Романтиканы таркатасың!

М а р а т *(усал караш ташлап)*. Синнән сораганнар ди кайда йөрергә икәнен! *(Үзен кыен хис итеп, шул ук вакытта каты гына.)* Берне маңып төшер идем дә, синең эше эт белән кул пычратасы килми. Йә этиеңә әләкләрсең!

Ф ә р и т *(кызып китеп, тора башлый)*. Ну күрсәтәм хәзер кирәгеңне!

Араларына Айгөл керә.



А й г ө л *(кычкырып)*. Фәрит, утыр урыныңа! Марат, юлыңда бул! Без сине монда чакырмадык.

М а р а т *(Айгөлгә үпкә тулы караш ташлап)*. Әйе! Сезнең күзләрегез акча белән томаланган. Ипиегезне эшләп алмыйсыз, шуның өстенә безнең кебекләрдән көлгән буласыз! Мәрхәмәтсезләр! Айгөл, синең дә шундый икәнеңне белмәгән идем. Чын дуслык мондый булмый ул! *(Кулын селтәп китеп бара.)*

А й г ө л *(яшь тулы күзләрен Фәриткә төбәп)*. Ялгыштык бугай...

Ф ә р и т *(Айгөлне кочаклап)*. Кит, шул чүп өчен борчылма әле! Әйдә, лучше мин сиңа чын ял итү нәрсә икәнен күрсәтәм!

А й г ө л. Кайда ул?

Ф ә р и т. Баргач күрерсең! *(Айгөлне клубка алып кереп.)* Менә бу ичмасам дөрес заведение! Әйдә биибез, Айгөл!

А й г ө л *(аптырабрак)*. Әйдә...

Ф ә р и т *(бар стойкасына барып, коктейль ала, Айгөлгә дә ала килә)*. Әйдүк, җаным! Эчеп кара әле!

А й г ө л *(бераз уйланып)*. Мин моны булдыра алмыйм, Фәрит. Гафу ит! Бер дә эчәсе килми.

Ф ә р и т. Кит инде, дускаем! Монда алкоголь юк диярлек, үзе тәмле. *(Коктейль сузып.)* Менә үзең кабып кара.

А й г ө л *(егеткә бик ошарга тырышып, эчемлекне бераз татып карый)*. Минем моңа кадәр эчкәнем юк иде! Ба! Шәп икән бит!

Ф ә р и т *(Айгөлне икенче бүлмәгә кертеп)*. Менә бу тагын да шәбрәк! *(Кесәсеннән ак порошоклы пачка чыгарып.)* Ну! Хәзер полный улет башланачак, былбылым. *(Ничек наркотикны кулланырга күрсәтеп.)* Хәзер синең чират!

А й г ө л *(бу юлысы Фәриткә кыюлыгын күрсәтер өчен)*. Синең өчен мин моны да кабып карарга әзермен! Әмма бу беренче һәм соңгы тапкыр.

Ф ә р и т *(кәнәфигә утырып)*. Әлбәттә! Тик беркемгә дә ләм-мим!

А й г ө л *(күзләрен йомып)*. Килештек! Тик барыбер ничектер күңел тыныч түгел. *(Икеләнеп, үз-үзенә.)* Ялгышрак булмады микән?

П ә р д ә.

## Икенче пәрдә

Расих абыйның эш бүлмәсе. Уң тарафта олы китап киштәсе. Киштә кырында өстәл, урындык, диван. Сул тарафта телевизор һәм кәнәфи. Р а с и х а б ы й һәм М и л ә ү ш ә а п а.

М и л ә ү ш ә а п а *(көрсенеп)*. Бәгърем, без кыләчәгебез ямьле, бәхетле булсын өчен шулхәтле көч түктек. Шулаймы?

Р а с и х а б ы й. Шулай.

М и л ә ү ш ә а п а. Кызларыбыз яхшы белем ала алсын, алдагы тормышта аларга җиңел булсын дип тырыштык. Дөресен сөйлимме?

Р а с и х а б ы й. Әйе, дөресен.

М и л ә ү ш ә а п а. Соң ни сәбәпле безнең бердәнберләребез күз алдында ялгыш юлга басалар? *(Өзгәләнеп.)* Ни булды аларга? Әллә соң без гаепле микән? Расих! Ник дәшмисең?

Р а с и х а б ы й. Миләүшәм! Кадерлем! Нәрсә әйтә алам соң мин? *(Кулларын җәеп.)* Белмим.

М и л ә ү ш ә а п а *(еламсырап)*. Тормыш, тормыш... Эх! Язмыштыр инде безгә яңадан-яңа киртәләр үсти! Элек акча булмаса да, гаилә тату иде. Ә хәзер... Хәзер берсе җилбәзәк! Мода дип саташа! Икенчесе...

Р а с и х а б ы й *(гаҗәпләнеп)*. Бәй! Айгөлгә ни булган?

М и л ә ү ш ә а п а. Менә шуның турында сөйләшергә кердем дә инде кырыңа.

Р а с и х а б ы й. Яле-яле! Нәрсә булды инде тагын?

М и л ә ү ш ә а п а. Айгөл кызыбыз... Ах! Тел дә әйләнми мондый сүзләр әйтергә! *(Елый башлый.)* Төннәрен кайтмый башлады! Беркөнне шыр исерек! Үзе туктый алмыйча көлә. Сиңа әйтмәдем инде. Чишендерә башлаган идем. *(Авыр сулыш алып.)* Кесәсеннән менә бу порошок килеп төште. *(Расих абыйга бәләкәй генә пакет суза. Күз яшьләрен тыя алмыйча.)* Кичә бүлмәмә керсәм, Айгөл чалбар кесәләренә минем бриллиант беләзек белән алкамны тыгып маташа! Әллә инде берәр әшәке компаниягә эләкте микән? Йөрәкләрем өзелеп киткәндәй булды инде.

Р а с и х а б ы й *(аптырап, кинәт кәнәфигә утырып)*. Кит! Булмас!

М и л ә ү ш ә а п а. Бәй, мин сиңа алдашып утырмамын инде! Нишләргә? Нинди чара табарга? *(Куллары белән башын тотып.)* Кайдан гына төште соң бу бәлаләр безнең башкайларыбызга? И-их!

Р а с и х а б ы й *(йөрәгенә кулын куеп)*. Мда-а-а... Зур бәла килде өйгә...

Шулар ук һәм А й г ө л белән Л ә й л ә.

Л ә й л ә *(кинәт ишек ачып)*. Әни! *(Туктап.)* Нәрсә булды? Нигә елыйсың?

Р а с и х а б ы й (әкрен, шул ук вакытта нык тавыш белән). Айгөл өйдәме? *(Ләйлә баш каккач.)* Чакыр.

А й г ө л *(кылтаеп кереп)*. Ма! Па! Ни булды тагын?

Р а с и х а б ы й. Утыр, Айгөл. Сүз озын булыр.

А й г ө л *(утырып)*. Ну?

М и л ә ү ш ә а п а. Кызым! Без барысын да беләбез.

А й г ө л *(белмәмешкә салышып)*. Аңламыйм. Нәрсә беләсез?

М и л ә ү ш ә а п а. Ни булды сиңа? Кая тәгәрисең син?

А й г ө л. Ә-ә-ә! Сез тагын минем шәхси тормышыма борыннарыгызны тыгарга әзерләндегезме?! Юк! Җитте!

Р а с и х а б ы й. Нәрсә сөйли бу бала?! Әллә акылыннан язганмы? Кайда күргән әйбер бу?! Мондый яшьтә ата-ана өенә исерек кайту! Әзрәк булса да оятың, хөрмәтең бармы синең?

А й г ө л *(кычкырып)*. Мин инде бала түгел!

Р а с и х а б ы й *(бүлдереп)*. Ата-ана өчен син һәрвакыт бала! Айгөл, ишетәсеңме?! Без сине дәвалау үзәгенә бирергә килештек.

А й г ө л. Мин алкоголичка түгел! Сез дә кайбер чакта шулай күңел ачасыз! Элек өйдә утыра торган гына яхшы кыз булганда, бер дә яннарыгызга чакырып сөйләшмәдегез! Ә хәзер инде мин үзем тыңлый белә торган дуслар, күңел ача торган чаралар таптым! Берегез дә кирәкми!

М и л ә ү ш ә а п а. Җитте! Тукта!

Айгөл ишекне бәреп чыгып китә.



М и л ә ү ш ә а п а *(үксеп)*. Әй Аллам! Нишләргә?! Нишләргә?!

Р а с и х а б ы й *(дару тамызып)*. Бетте, хатын! Көчләп дәваханәгә алып барачакбыз!

М и л ә ү ш ә а п а. Син күрдеңме соң? Сиңа әйтәм! Нинди нәфрәтле иде аның күзләре! Ә син һаман үзәк тә үзәк дисең.

Р а с и х а б ы й. Ә син нәрсә тәкъдим итәсең соң?

М и л ә ү ш ә а п а. Ул бит бездән тагын да читләшәчәк! Упкын бит! Арабызда упкын! *(Үксеп елый.)*

Р а с и х а б ы й *(хатынының кулын тотып)*. Миләшем, ышан миңа! Без аны аякка бастырырбыз. Әле соң түгел!

М и л ә ү ш ә а п а *(яшьләрен сөртеп)*. Ничек, Расих? Ничек?

Р а с и х а б ы й. Тынычлан, зинһар, шаулама. *(Бераз уйлап торганнан соң, пышылдап.)* Менә без болай итәрбез! Минем бер яхшы таныш врачым бар. Шуның белән сөйләшеп алырга кирәк булыр. Янәсе, минем йөрәгем түзмәгән һәм «Скорый»да больницага алып киткәннәр.

М и л ә ү ш ә а п а. Кит, тузга язмаган сүз сөйләп утырасың мондый чакта да!

Р а с и х а б ы й. Тукта инде, ахырга чаклы тыңлап бетер! Мин эшемнән отпуск алырмын һәм әзрәк больницада ятып чыгармын. Айгөл аңлар дип уйлыйм инде кем аркасында минем больницага эләгүемне. Ә? Шәпме?

М и л ә ү ш ә а п а. И-и-и! Аңласа ни! Аңа барыбер булмасмы соң?

Р а с и х а б ы й. Руслар әйткәндәй, попытка не пытка инде ул, карчык!

М и л ә ү ш ә а п а *(әкрен генә)*. Ярар, синеңчә булып торсын әлегә. Килеп чыкмаса инде, дәваханәгә алып барырбыз.

П ә р д ә.

## Өченче пәрдә

Өйдәге кунаклар өчен бүлмә. Сәхнә уртасында диван. А й г ө л белән Л ә й л ә утырып тора.

Л ә й л ә. Фәрит, син акыллы егет. Яшермә миннән, зинһар, әйт.

Ф ә р и т *(кәнәфидә җәелеп утырып)*. Ләйлә, син шундый матур, рәхәтләнеп ял итәр урынына юк-бар белән башыңны ватасың!

Л ә й л ә. Син миннән нәрсәдер яшерәсең! Айгөл синең белән аралаша башлагач үзгәрде! Ә хәзер... ул чит. Син! Син аның башын чуалттың!

Ф ә р и т *(иснәнеп)*. Ул үзе минем арттан иярде. Мин аны көчләп эчәргә дә, күңел ачарга да өйрәтмәдем. Чынын әйткәндә, туйдырды инде ул мине! Тик акча сава торган сыерым булды инде минем! Айгөл миңа кирәк! Кыяфәте дә бик әйбәт, бөтен теләгәнемне табып бирә, нәрсә әйтсәм, шуны эшли! Юләр булырга кирәк, андый кызны ычкындырсаң! *(Йодрыгын йомарлап.)* Ә ул минем менә кайда!

Л ә й л ә. Зинһар, җибәр аны! *(Елый башлап.)* Калдыр! Тимә!

Ф ә р и т. Кызыксың син! Кайдан тагы акча табыйм? Юк! Әлегә кирәк ул миңа.

Л ә й л ә *(кызып)*. Тәк! Син яхшыча әйткәнне аңламыйсың инде, әй! Алайса, мин болай эшләрмен! Айгөл шулхәтле синең белән мавыккан! Телефонында гел синең генә фотоларың!

Ф ә р и т *(көлеп)*. Тапты куркытыр әйбер!

Л ә й л ә *(хәйләкәр елмаеп)*. Анда синең наркотик дозасы кадаган чагың видеога төшерелгән, һәм ул кадрлар инде миндә! Шулай ук бер егеткә героин сатканың да сурәтләнгән! Менә хәзер эләктең, малай!

Ф ә р и т *(шунда ук җитди кыяфәт белән)*. Син юри генә әйтәсең! Мин чынлап та шулай иткән идем, тик син моны барыбер исбат итә алмаячаксың!

Л ә й л ә *(кесәсеннән диктофон чыгарып)*. Менә хәзер чын-чынлап эләктең!

Ф ә р и т *(агарынып)*. Ярар! Синеңчә булсын! Тик онытма! Мин моны болай гына калдырмаячакмын!

Л ә й л ә *(үз-үзенә)*. Вәт шайтан! Башта нинди интересный булып күренгән иде. Мда! Заманалар үзгәрә! *(Бүлмәдән урамга чыга. Маратны күрә.)*

Ләйлә һәм Марат.

Л ә й л ә. Марат! Сәлам! Хәлләрең ничек?

М а р а т *(коры гына)*. Ярыйсы әле.

Л ә й л ә *(бераз эндәшмичә торып)*. Минем бүтән ярдәм сорар кешем юк. Зинһар өчен, сүземне азакка хәтле тыңла. Аннары үзең карарсың инде, кирәкме ул сиңа, юкмы.

М а р а т *(эскәмиягә утырып)*. Ярар, тыңлыйм.

Л ә й л ә. Мин электән сине беләм. Безнең ара беркайчан да җылы булмады. Монда күбрәк мин гаеплемендер, ләкин хәзер сүз минем турында түгел. *(Әзрәк уйларын тәртипкә китереп.)* Син Айгөл белән кечкенәдән аралашасың, характерын миннән дә яхшырак беләсең.

М а р а т. Юк, Ләйлә. Син ялгышасың. Белә идең, дисәң, дөресрәк булыр. Ул хәзер гел икенче!

Л ә й л ә. Менә шуның турында сөйләшәсем килгән иде дә инде. Айгөл Фәрит белән чуала башлаганнан бирле кинәт үзгәрде. Әти-әни нишләтергә дә белмиләр! Беркөнне әтинең йөрәге тотты! Хәзер больницада! Ә Айгөл һаман күңел ачып йөри. Мин аның наркотиклар кулланганын да беләм.

М а р а т *(агарынып)*. Наркотиклар!.. Айгөл... Башка сыеп бетми! *(Ярсып.)* Син чынлап та беләсеңме, әллә шулай уйлыйсың гынамы?

Л ә й л ә. Юк! Үз күзләрем белән күрдем! Нишләргә, Марат?

М а р а т *(дулкынланып)*. Мин аны туры юлга бастырыр өчен бөтен көчемне бирәчәкмен! Айгөлнең бүген үк күзен ачарга кирәк. Ул ничәдә өйдә була?

Л ә й л ә *(рәхмәтле күзләрен төбәп)*. Биштә.

М а р а т *(эскәмиядән торып)*. Мин сезгә бүген килермен.

Л ә й л ә. Тукта!.. *(Башын аска иеп.)* Рәхмәт. Гафу ит мине элеккеге хаталарым өчен...

М а р а т. Нинди хата? Мин бернәрсә дә хәтерләмим. *(Елмаеп, кулын Ләйләнең иңенә куя.)* Юк белән башыңны катырма! Иң мөһиме – Айгөл!

Л ә й л ә *(шатланып)*. Рәхмәт. Рәхмәт сиңа, Марат!

М а р а т белән А й г ө л.

А й г ө л. Ә! Сәлам! Бу син икән! Мин инде яңа дусларым дип торам.

М а р а т. Бәй, син эреләндең инде хәзер! Иске танышларыңны гел оныттың. Тик яңа дус табам дип пешә күрмә!



А й г ө л *(елмаеп)*. Ярар инде, кызма! Шаяртырга да ярамый үзең белән!

М а р а т. Мин уенчык түгел шул!

А й г ө л. Булды-булды! Гафу ит! *(Марат кырына килеп.)* Чынлыкта, килгәнеңә бик шатмын! *(Бармак янап.)* Нигә безгә гел керми башладың?

М а р а т. Йә сиңа яңа дуслар табарга комачаулармын.

А й г ө л. Нәрсә ошамый соң сиңа аларда? Бәйләндең инде шуларга!

М а р а т. Әгәр алар сине әшәкелеккә өйрәтмәсәләр, минем бер сүзем дә юк.

А й г ө л. Әллә юри инде барыгыз да шул ук бер әйберне тукыйсыз! Мин сайлый белмим дисеңме?

М а р а т. Тәк. Аңлашылды. Мин сиңа ни әйтсәм дә барыбер. Алай булгач, мин монда кирәк тә түгел. *(Ишеккә таба атлый.)*

А й г ө л *(каршына төшеп)*. Юк инде, мин сине мондый кәеф белән җибәрмим.

М а р а т *(кире борылып)*. Әйдә ачыктан-ачык сөйләшик әле.

А й г ө л. Мин риза! Дөресен әйткәндә... Марат, мин буталып беттем! Кайда карама, мин гаепле! Әти минем аркада... *(Туктап калып елый башлый.)* Ике көн элек... *(Тотлыга-тотлыга.)* Нинди яхшы күңелле кыз иде! Үлде! Передозировка! Мин аны бу пычраклыкка, наркотикларга өйрәткән идем! Аңлыйсыңмы, Марат? Фәрит мине бүген ташлады! Яшәүнең мәгънәсе калмады! *(Марат Айгөлне кочаклый.)* Юкка гына чыкты башкайларым!

М а р а т *(Айгөлне башыннан сыйпап)*. Тынычлан, дустым. Әле дә соң түгел!

А й г ө л *(яшьле күзләрен күтәреп)*. Чынмы?

М а р а т *(ышанычлы тавыш белән)*. Чын, Айгөл, чын. Ләкин булганнарны, хаталарыңны төзәтү авыр булачак!

А й г ө л. Аһ, нишләрмен инде? Ничек әтиемә, әнием, апам күзенә күренермен? Алар миннән бизделәр бит. Ә теге кыз... *(Тагын елый.)*

М а р а т. Аны инде кайтарып булмый. Ә туганнарың барыбер сине яраталар. Гаиләдән дә якын кешеләр юк! Син ялгышсаң, алар гына сине гафу итәрләр һәм яратырлар, беркайчан да элекке хаталарны искә төшереп таламаслар. Гаилә – синең иң ныклы терәгең!

А й г ө л *(бераз тынып торганнан соң)*. Син бик акыллы, Марат. Чынлап та, бигрәк нык ялгышканмын икән! Күзләрем яңадан ачылып киткән сыман... Син булмасаң, нишләр идем?

М а р а т. Айгөл, вакытында хатаңны аңладың! Ә хәзер инде киттек гаиләң кырына! Аларны шатландырыйк.

Кулга-кул тотынышып сәхнәдән чыгып китәләр.
П ә р д ә.

## Дүртенче пәрдә

Клуб. Сәхнәдә бар, урындыклар. Пәрдә күтәрелгәндә, Фәрит дусты белән сыра эчеп утыра. Ф ә р и т һәм Х а л и т.

Ф ә р и т *(кружканы корытып)*. Ну, друган! Прикинь! Ул, шул чүпрәкбаш, кемне диген әле, иң матур булган егетне кыек тәпи Чәукә малаена алыштырды! Минем тырнак очына да тормаган чүпкә!

Х а л и т. Хатын-кызлар җүләр бит алар. *(Телен көчкә әйләндереп.)* Син моны болай гына калдырма.

Ф ә р и т *(өстәлгә сугып, ямьсез тавыш белән)*. Дөрес, Халит! Котелогың әшли икән, ә! Минме? Мин! Искә алдыртам әле исемемне!

Х а л и т *(Фәритнең җилкәсеннән кагып)*. Правильно, браток! Синең белән минем кебекләр справедливостьны торгызырга тиешләр!

Ф ә р и т. Во! Шәп әйттең!

